ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2024 ел Баулы шәһәре №76

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуларын таныргa:

- 2021 елның 30 июлендәге 115 номерлы «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» (2023 елның 25 апрелендәге 104 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2021 елның 30 июлендәге 118 номерлы «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» (2022 елның 4 апрелендәге 61 номерлы, 2023 елның 13 мартындагы 62 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2021 елның 30 июлендәге 119 номерлы «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» (2023 елның 22 февралендәге 51 номерлы, 2022 елның 12 апрелендәге 70 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2021 елның 30 июлендәге 123 номерлы «Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»;

- 2021 елның 30 июлендәге 127 номерлы «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»;

- 2021 елның 30 июлендәге 141 номерлы «Җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» (2023 елның 25 апрелендәге 105 номерлы, 2024 елның 19 февралендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2021 елның 30 июлендәге 174 номерлы «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системасында булган мәгълүматларны, документларны, материалларны күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (2023 елның 22 февралендәге 52 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров